Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

Ислам нуры

№ 20 (648) 27 октябрь, 2017 ел (1439, Сәфәр) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

# Туган тел сагында

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин социаль челтәрләрдә татар телен яклап чыгып, мәгълүмати кампания башлап җибәрде. Үзенең инстаграмдагы рәсми битендә мөфти хәзрәтләре бөек мәгърифәтче һәм дин галиме Каюм Насыйриның туган телне яклап әйткән “Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел”, - дигән сүзләрен китереп, милләттәшләрен һәм дин кардәшләрен ана телебезне яратырга чакыра.

“Татарчаң такы-токымы? Юкка ояласың! XIX гасыр татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый үзенең бер шигырендә дүрт телне кушып язган:

Чи хуш бән мөәйяд, тарилдә орех,
Вә ин ләм йөәккәл, булыр ул грех.

Ягъни “тәлинкәдәге чикләвекләр шундый яхшы, ашамый калсаң гөнаһы булыр”. Ничек беләсез, шулай аралашыгыз. Тик туган телегезгә мәхәббәтегезне генә җуймагыз. Ватык-җимерек сөйләмне тыңлый алмаган милләттәшләребезгә исә аерым мөрәҗәгать итәсем килә: биздермәгез кешене ана теленнән! “Чыктым аша күпер” булса да, ярты сүзе русча булса, сөйләсен. Яшәсен татар теле!” - диелә Камил хәзрәтнең битендә.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләре буенча киңәшмә дә үткәрде. Нәтиҗәдә мөфтияттә татар телле мохит булдыру, мәчетләрдә татар телен өйрәнү буенча “Без — татарлар” укыту программасын кертеп җибәрү турында карарлар кабул ителде.



20 октябрьдә Казанның “Галиев” һәм “Тынычлык” мәчетләрендә укылган җомга вәгазьләре тулысынча татар телен саклау һәм үстерүнең кирәклеге, өммәт өчен иминлек, бердәмлектә яшәүнең әһәмиятен аңлатуга багышланды. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм имам Тимергали хәзрәт Юлдашев дин кардәшләренә телнең әманәт һәм милләтнең иң беренче мөһим билгесе булуын үтемле мисаллар китереп аңлатырга тырышты.

“Туган телне өйрәнегез, дин кардәшләр!” Вәгазьләр шул сүзләр белән тәгәлләнде.

**(ТР МДН сайтыннан)**

# Иман нуры булса...

Октябрь аенда Ырынбур шәһәренә булган сәяхәтебез гаҗәеп якты кешеләр белән очрашырга мөмкинлек бирде. Гасырлар буе үз йөзен югалтмый саклап килгән атаклы “Хөсәения” мәчете белән якыннан танышу да онытылмаслык мизгелләр бүләк итте. Әлеге мәчетне һәм мәчет каршындагы мәдрәсәне 20 йөз башында Оренбургның беренче гильдия сәүдәгәрләре Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлар үз хисапларына оештыра. Аны уңышлы тәмамлаган шәкертләрне миллионер Хөсәеновлар үзләре стипендия билгеләп, чит илләргә дә укырга җибәргәннәр. «Хөсәения»дә укып, алдынгы карашлы һәм белемле шәхес булып җитлеккәннәр арасында Зәки Вәлиди, Сәгыйть Рәмиев, Ильясбәк Кудашев-Ашказарский, Мирхәйдәр Фәйзи, Афзал Таһиров, Шамил Усманов, Шәехзадә Бабич, Муса Җәлил кебек күпләргә яхшы таныш исемнәрне очратырга мөмкин.



*Атаклы “Хөсәения” мәчете.*

1931 елларда заман шаукымына эләгеп, ябылуга дучар ителгән мәчет туксанынычы елларда кабат аягына баса. Бүген ул — Оренбургның тарихи ядкаре генә түгел, кабат үзенең изге вазыйфасында. Сүз уңаеннан: өлкәнең мөфтие — Әлфит хәзрәт Шәрипов, “Хөсәения” мәчетенең имам-хатыйбы — Руслан хәзрәт Әхмәров.

Шунысы куанычлы: 21 гасыр башында да Ырынбурда Хөсәеновлар кебек милләттәшләребез юк түгел. Аларның берсе — Мөхтәр Галиулла улы Хәсәнов. Шәхси эшмәкәр булса да, үзенең шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгыртмыйча, татар милләте өчен күпне эшләгән олы җанлы шәхес. М.Фәйзи исемендәге татар дәүләт драма театрына даими ярдәм күрсәтеп торуы, алай гына да түгел, театр каршында махсус хәйрия фонды булдыруы да фәкать мактауга гына лаек. Үзенең туган ягы — Беләй районы Алабайтал авылында, этисенең энесе Хөсәен Хәсәнов гаиләсе белән берлектә, мәчет төзелешенә зур ярдәм күрсәтүе дә Аллаһ ризалыгы өчен эшләнгән гамәл. Хәер, Мөхтәр абый үзе кылган изгелекләр турында күкрәк кагарга яратмый: “Мин бит Хөсәенов түгел, Хәсәнов кына”, - дип сүзне елмаюга бора.

Оренбург шәһәре «Туган тел» татар милли-мәдәни мөхтәрияте җитәкчесе Рөстәм Фәйзерахман улы Маннанов — тумышы белән Сакмар районы Үрге Чебенле авылы егете. Белгечлеге медицина белән бәйле, шул ук вакытта төбәктә “Сәлам” хәләл туклану челтәре булдырган эшмәкәр дә ул. Шушы исемдәге кафеда да, кибетләрендә дә — хәләл ризыклар. “9 ел элек, Төркиягә баргач, андагы матурлыкка, мохиткә шаккатып кайткан идем. Менә шуннан соң үзебездә дә хәләл ризыклар булдыру турында уйлана башладым. Эш башлаганда, Алланың ярдәме белән, бернинди киртәләр булмады, проект өчен администрациядән дә беркадәр акча бүленеп бирелде. Бүген инде, Аллага шөкер, үзебезнең патент алган сәүдә маркабыз, төбәктә үз урыныбыз бар. Шәһәр халкын да, кунакларны да, чит ил делегациясен дә хәләл ризыклар белән сыйлыйбыз. “Чаллы-бройлер” компаниясе белән дә эшлибез. Шушы юнәлештә эшли башлагач, әкренләп үзем дә исламга якынайдым, намазга бастым”, - дип үз фикерләре белән уртаклаша Р.Маннанов.



*Мөхтәр Хәсәнов китапханәдә очрашуда.*

Уй-ниятләре дә, кылган гамәлләре дә иман нуры белән өртелгән шушындый егетләребез күбрәк булса, никадәр көчле һәм аягында күкрәп басып торган милләт булыр идек без...

**Айгөл Әхмәтгалиева**.



*Сулдан беренче – Руслан хәзрәт Әхмәров, сулдан өченче – Рөстәм Маннанов.*

# Тарихта эзебез калсын

Бөек Аллаһы Тәгалә минем кебек мескен колына олуг хаҗ гамәлен кылырга насыйп итте. Һәм без Аллаһы Тәгаләнең бу мәрхәмәте өчен Аңа бик рәхмәтле булырга тиешбез. Аллаһы Тәгалә әйтә: ***"Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, шөкер итмәсәгез, газабым каты булыр"***, - ди (Ибраһим сүрәсе, 7).

Чыннан да, Аллаһы Тәгаләнең йортына бару, Кәгъбәтуллаһ тирәли тәүәф кылу, Гарәфә тавында догада булу — болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең рәхимлеге, шәфкате! Ул бар кешегә дә бирелми. Күпме кешеләр, мөселман булсалар да, бер тапкыр да Аның йортына барып хаҗ кылмый бу якты дөнья белән хушлашалар. Аллаһы Тәгаләнең хаҗ кылырга өндәвенә җавап бирми бу дөньядан китеп баралар. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Алар җәяү, җайдак көе Минем яныма килсеннәр" (Хаҗ сүрәсе, 27). Алар әйттеләр: "Йә Аллаһ, мин Синең каршыңда, мин Синең чакыруыңа җавап бирдем, Син мине чакырдың, һәм мин килдем". Хаҗ кылучылар арасында хаҗ кылырга чыгып китеп тә, хаҗ җирләренә барып җитә алмаганнар һәм шулай ук хаҗ кылып та, газиз туганнары янына кире кайтып җитә алмаганнар да бар.

Хаҗ, чыннан да, Ахирәт көнен хәтерләтә! Дөньяның төрле почмакларыннан мөселманнар бер урынга җыелалар. Быел ике миллион ярым кеше хаҗ кылган. Хәрәм мәчетенең балконыннан аларның барысын күреп, таң каласың! Менә Индонезиядән зур гына делегация яныңнан узып китә, алар артыннан Төркия, Мисыр, Америка, Нидерландия, Англия мөселманнары, әләмнәрен күтәреп, узып китәләр. Өсләрендә гаурәтләрен каплаган ике сөлгедән башка һичнәрсә юктыр. Өметләре бары бер: Аллаһы Тәгаләнең гафу итүе. Боларны бу дөнья мәшәкатьләре дә, эш тә, акча да кызыксындырмый. Алар арасында президентлар да, зур-зур армия генераллары да, танылган галимнәр дә бардыр. Әмма шушы ике кисәк сөлге белән төренгәннәр арасыннан син аларны белмәссең. Алар бары тик Аллаһы Тәгаләнең гафу-кичерүләрен өмет итеп килгәннәр.

Ә тәүәф кылуы ни тора!!! Меңләгән кеше Кәгъбәтуллаһ тирәли әйләнә. Шулхәтле тыгыз баралар, кайвакыт көчкә сулыш аласың, күкрәк кысыла. Аякларыңның кая басканын да белмисең, кеше агымы сине үзе илтә. Ә кешеләр, шушылай кысылып, кем шатлыгыннан, кемнәрдер кылган гөнаһлары, хәрәмнәре, кылган начар гамәлләре, калдырган намазлары өчен чын күңелдән үкенеп, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итеп, үксеп-үксеп елыйлар. Аларның монда килә алуларына сөенечләреннән йөзләре балкый, күзләрендә шатлык, алар Кәгъбәтуллаһтан аерыла алмыйлар. Шулай ук, күп сугышлар, туганнарын югалту, зур кайгы-хәсрәт кичергән кешеләрнең күзләрен күреп, аларның Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә мохтаҗлыгын, өметләрен тоясың. Аларның күзләре, әйтерсең лә, сабый баланың әнисенең яклавын, ярдәмен өмет иткән күзләрен хәтерләтә.

Шуңа күрә: "Аллаһы Тәгалә монда килергә насыйп иткән икән, димәк, Ул сезне сайлап алган, һәм Ул сезне ярата", - дим мин хаҗиларга. Чөнки Аллаһ сезне Үз өенә чакырып китергән! Сез Аның кунаклары!

Ә хәзер хаҗга бармаганнарга сорау бирәсем килә. Ни өчен сез Аллаһы Тәгаләнең чакыруына җавап бирмисез? Аллаһы Тәгалә сезне Үз өенә чакыра, ә сез бармыйсыз. Еллар үтә, сез һаман да яңадан-яңа сәбәпләр табасыз. Миңа әле иртәрәк... Минем иманым саерак әле… Көчем җитмәс… һәм башка сәбәпләр табыла. Аллаһы Тәгалә сине төзәтсен һәм Үз йортына китерсен.

Хаҗ кылучыларның хаҗларын кабул итсен!

Быел инде мин җиденче тапкыр хаҗ кылдым. Әмма бу хаҗ вакытында гаҗәеп бер вакыйга булды. Хәлемнән булдыра алганча, мин Мәккә шәһәрендәге "Әл-Хәрәм" китапханәсендә булырга, китаплар укырга тырыштым. Күз алдына китереп карагыз әле бу китапханәне: 14 мең ел буе ислам галимнәренең төрле өлкәләрдә язылган фәнни хезмәтләрен җыйган, меңнәрчә китапны сыйдырган бик зур китапханә бу! Мин анда һәркөнне бардым һәм һәр барган саен бу китаплардан ниндидер яңалык алып кайттым.

Көннәрдән беркөнне шушы китапханәдә утырганда өстәлдә яткан бер китапка күзем төште. Әйтерсең лә аны кемдер махсус минем өчен калдырган! Ул китап "Бу гасырда тарихта онытылган бөек кешеләр" дип атала иде. Мин, кызыксынып, кулыма алдым, битләрен актара, укый башладым. Анда гыйлем хәзинәсенә зур өлеш керткән, берсеннән-берсе зур гарәп галимнәре турында язылган иде. Китапны укый торгач, мин "Бөек сәяхәтче һәм Ислам диненә өндәүче. Диңгезләр гизүче чын Синдбад" дип башланган юлларга юлыктым.

Чиксез гаҗәпләнүемнең сәбәбе — шушы китапта язылган Габдеррәшид Ибраһим дигән кешенең ТАТАР булуы! Әйе, җәмәгать! Аның татар булуы! Сөбехәналлаһ! Дөнья масштабындагы галимнәр белән беррәттән Хәрәм мәчетендә бөек татар сәяхәтчесе һәм Ислам динен таратучы татар турында укуым иде.

Габдеррәшид Ибраһим 1846 елда Себердәге Тара җирлегендә туган. Безнең балалар кебек үк кечкенәдән мәчеттә Коръән һәм хәдисләр өйрәнеп үскән. Гыйлем эзләп, укуын дәвам итү өчен, ул уникe яшендә Мәккә һәм Мәдинә якларына чыгып китә. Егерме ел буена Мәккә һәм Мәдинәдә гыйлем ала ул. Күз алдына гына китереп карагыз әле, уникe яшьлек бала, гыйлем эзләп, ерак Мәккә, Мәдинә шәһәрләренә чыгып китә һәм бик озак еллар дәвамында белем алып, шуннан соң гына туган ягына, Рәсәйгә кайта. Аның Рәсәйгә кайтуы бик зур шау-шу тудыра. Габдеррәшид Ибраһимнең кайтуын ишетеп, илнең төрле почмакларыннан мөселманнар җыела башлый. Ул мәчет-мәдрәсәләрдә дәресләр алып бара, бик күп фәнни мәкаләләр яза. Патша хакимлек итүче Рәсәйдә сәяси проблемалар, четерекле мәсьәләләр туа башлый. Шуңа күрә Габдеррәшид Ибраһим Төркиягә китәргә мәҗбүр була. Төркиядә аны мөселманнар зурлап каршы алалар. Бераздан соң ул тагын Рәсәйгә кайтып, үз халкына дин дәресләрен укыта, китаплар яза башлый. Аллаһы Тәгалә аңа тагын сынау җибәрә. Һәм ул ерак сәяхәткә китәргә мәҗбүр була. Кемдер бу сынауларга түзми, тормышның кагуы дип, эшен ташлар иде, әмма ул кеше Габдеррәшид Ибраһим булмас! Бу хакта аның үзенең төпле фикере була.

Габдеррәшид Ибраһим дингә чакыру нияте белән Ерак Көнчыгышка юл тота. Башта ул Монголиядә туктала. Аннан Кытайга, Малайзиягә, шуннан соң Индонезия, Сингапур, Һиндестан, Кореяга барып җитә. Шулай ук бу елларда ул хаҗ да кыла. Ерак Көнчыгышта аның даны киң тарала. Хәтта христиан миссионерлары "Кытай җирләрендә христиан дине таралуга каршы килүче дошман бар һәм бик күпләр аның диненә күчәләр", - дип, үзләренең җитәкчеләренә зарланалар. Кем соң ул дошман дип сорагач, Габдеррәшид хәзрәт Ибраһим, диләр.

Менә нинди кызыклы вакыйгалар була аның белән: Кореядә яшәгәндә, кытайлыларның корея халкын кол урынына иң авыр эшләрне эшләргә мәҗбүр иткәннәрен күреп ала. Кореялеләрнең бары тик бераз йоклап алырга гына вакытлары кала, калган вакытларын алар кытайлылырга хезмәт итеп үткәрәләр. Бервакыт поездда барганда Шәих бер корея кешесеннән милләтенең киләчәген ничек күрүе турында кызыксына. Кем белән генә очрашмасын, Габдеррәшид Ибраһим: "Халкыңның, милләтеңнең киләчәген кичек итеп күз алдына китерәсең?" - дип сорый торган булган. Бу корейле: "Безнең милләтебез хайваннар дәрәҗәсендә. Мин аның киләчәген күрмим",- дигән. Йөз ел элек, чыннан да бу милләт бик түбән дәрәҗәдә булган. Аның киләчәген бүгенге чәчәк атып утыручы, югары дәрәҗәдәге икътисадлы, иң алга киткән илләр исемлегендә йөрер дип кем күз алдына китергә?!. Мисал өчен бер-ике мәгълүматны китерү дә җитә: 1980 елдан ике меңенче елга кадәрге фәнни ачышларның саны ундүрт мең бу илдә. Ә барлык гарәп илләрендә шул ук вакытта бары тик дүрт йөз генә.

Әйткәнемчә, Габдеррәшид шәих ерак сәяхәткә чыга. Ул Сингапур, Монголия, Кореядә булганнан соң Японияга җитә. Япониядәге халыкның чисталыгын, яхшы холкын, кунакчыллыгын, турылыгын, тугрылыгын күреп исе китә. Барыннан да бигрәк бу халыкның ислам динен кабул итәргә әзер булуын күреп гаҗәпләнә. Моны ул министрлар, әйдәп баручы җитәкчеләр белән күрешкәч төшенә. Япониядә ул парламентта, университетларда, мәктәпләрдә, сәүдә йортларында, базарларда, хәтта төрмәләрдә дә халыкны ислам диненә чакыра. Ул үзен бик гади тота, кешеләр белән тиз уртак тел таба. Кем генә булмасын, ислам диненә чакырып, сәгатьләр буе ислам дине турында сөйли ала. Аның чакыруына җавап итеп, күп кенә японлылар ислам динен кабул итәләр. Моның өчен ул махсус япон телен өйрәнә. Габдеррәшид шәих сәбәпчелеге белән бик күп мәчетләр төзелә, меңнәрчә кеше ислам динен кабул итә. Япония ислам динен илнең рәсми диннәре дәрәҗәсенә куя.

Ислам дине тарихчысы Мөхәммәд Рәджәб аль-Байуминың Габдеррәшид шәих турында әйткәннәрен китерәсем килә: "Токиога килгән мөселман иртәнге намазга мәчеткә барса, гаҗәеп бер нәрсә күрер иде. Ул 95 яшьлек өлкән яшьтәге кешенең, иртәнге намаз башланырга берничә сәгать алдан килеп, иртәнге намазга кадәр намаз укуын, аннан иртәнге намазны имам булып үткәрүен күрер иде. Бу мөхтәрәм кеше зекер әйтүдән туктау белән, иртән кояш чыкканчыга хәтле, аны бик күпләр Коръәнне тәфсир кылуны һәм Пәйгамбәребез (г.с.) хәдисләрен тыңлар өчен уратып алуларын күрер иде. Шуннан соң ул, инде өлкән яшьтә булуына карамастан, мәчет янында төзелгән мәдрәсәгә юл тотар һәм анда балаларга Коръән, гарәп теле нигезләрен, Пәйгамбәребез (г.с.) хәдисләрен өйрәтү белән мәшгуль булыр. Ә бит ул үзеннән өч буын кечерәкләрне өйрәтә."

Габдеррәшид Ибраһим Япониядә, 1944 елны, инде йөз яшенә җиткәндә бу дөнья белән хушлаша. Безнең милләтебезнең бөек батыры ул! Үзенең бөтен гомерен Ерак Көнчыгыштагы мөселманнарның ислам дине турында ишетүләре, ислам динен кабул итүләре, аны өйрәнүләре өчен корбан иткән чын герой! Ул үзенең автобиографиясен "Аламу Ислами" (Ислам дөньясы) дип аталган ике томда язган. Ислам дине галимнәре бу хезмәткә бик югары бәя бирәләр.

Габдеррәшид Ибраһим турында укыгач, минем күзләрем яшь белән тулды. Дөнья күләмендә дан тоткан ислам галимнәре мөселманнарга үрнәк итеп куя торган бу бөек шәхес турында мин Мәккәгә барып беренче тапкыр белдем! Моңарчы минем бу бөек татар галиме аның турында ишеткәнем дә юк иде.

Бездән алда килгән буыннар безгә саф, чиста динебез килеп җитсен өчен күпме көч куйганнар, үзләренең гомерләрен корбан иткәннәр. Шушы тырышлыклар белән динебез безгә саф, гүзәл көе килеп җиткән. Әмма аларның хезмәте, без бу эшне дәвам итмәсәк, безгә бернинди файда бирмәс. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Бу өммәт дөньядан үтте. Алар лаек булганнарын алырлар, ә сез үзегез лаек булганны алырсыз. Вә сез аларның кылган гамәлләре өчен соралмассыз" (Бәкара сүрәсе, 134).

Менә мондый сорау туа: безгә хатыннарыбыз шушындый батыр балалар таба алмыйлармы әллә? Без, әти-әниләр, шушындый яңадан-яңа батырларны тәрбияләп үстерә алмыйбызмы әллә? Ә без, укытучылар, Габдеррәшид, Риза Фәхретдин, Шиһабетдин Мәрҗани, Кол Шәриф кебек көчле шәхесләр, ныклы буын тәрбияли алмыйбызмы әллә? Көчсезләндекме әллә без? Юк! Без көчсезләнмәдек! Без көчсез түгел! Без Коръән юлыннан барырбыз! Без — мөселманнар, диндә дә, икътисадта да, сәясәттә дә, спортта да иң көчле, алда баручы мөселманнарыбыз белән горурланырга телибез! Алда баручы мөселманнар булуыбыз белән горурланырга телибез!

Сентябрь башыннан мәктәпләрдә, техникум, университетларда укулар башланды. Безнең балаларыбыз белем алырга уку йортларына юнәлделәр. Әмма ни аяныч, аларның күбесе ник укыганнарын да аңламый, белем алуның ни өчен кирәклеген дә төшенеп җитми. Кадерле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләнең яраткан колына әйләнү өчен, безнең җәмгыятебезне алга этәрү өчен ихласлык, тырышлык кирәк. Әле бер ел элек кенә гарәп хәрефләрен дә белмәгән, ә бүген гарәпчә йөгереп, аңлап укучы тырыш кешеләрне беләм мин. Аларның кайберләре үзләре хәзер гарәп телен укыта. Каян шундый дәрәҗәгә ирешкән соң алар? Бу бары тик белем алуда нык тору, тырышлык һәм теләп өйрәнү нәтиҗәсе.

Әйткәнемчә, кояш туктап тормый, көн артыннан төн җитә. Көн артыннан көн үтә. Шулай безгә бирелгән вакытларыбыз үтә бара. Уйланыйк әле, артыбыздан ни калдырабыз соң без? Аллаһы Тәгаләнең хак динен үстерү өчен нинди өлеш кертәбез? Динебез алга китсен өчен нинди файда китерәбез?

Кадерле дин кардәшләрем, без иң яхшы җәмгыять! Аллаһы Тәгалә безне Үзе караңгылыктан гыйлем яктылыгына чыгарган, Аллаһның тыйганнарыннан ваз кичеп, бер Аллаһка буйсынуны төшендергән безгә. Әйдәгез соң, калганнарга үрнәк булыйк, онытылмаслык үрләргә ирешик. Тарихта эзебезне калдырыйк.

Әлһәмдулиллаһ, ике ел инде балаларыбыз мәчеттә Коръән өйрәнә. Шушы үткән ике ел эчендә 3-4 җүз ятлаган балаларыбыз бар. Быел да яңа төркем җыябыз. Балаларыбызны Йосыф хәзрәт өйрәтәчәк. Ул балаларыбызны Габдеррәшид һәм башка тугры буыннарга охшаш ныклы шәхесләр итеп тәрбияләр өчен бөтен көчен куяр дип ышанып калабыз. Амин йа Раббым.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

## ӘДӘБИ СҮЗ

*Гөлүсә Батталова*

### Безнең язмыш

*Безнең тарих фаҗигале,*
*Безнең язмыш яралы.*
*Безгә тәкъдир насыйп иткән*
*Актан бигрәк караны.*

*Кылычтан үткән кавем без,*
*Ватаныннан куылган.*
*Дөньяны яулар көчебез*
*Җир йөзеннән җуелган.*

*Богауланган горурлыгы,*
*Тарайтканнар ызанын.*
*Күпне күргән халкым, әмма*
*Югалтмаган иманын!*

*Онытмаган бисмилласын*
*Манаралар ауганда.*
*Аллам диеп яуга кергән*
*Күктән кургаш яуганда.*

*Калдырмаган уразасын,*
*Калдырмаган намазын,*
*Бер ишетергә тилмереп,*
*Тансык азан авазын.*

*Мең кат үлеп терелгән без,*
*Мең кат көлдән ягралган.*
*Имансызлар арткан саен,*
*Бездә иман яңарган.*

*Кемнәр безгә кизәнмәгән,*
*Кемнәр безне сатмаган...*
*Ничек исән калыр идек —*
*Безне Алла саклаган.*

### Уч төбемдә – өмет

*Каешланган күптән инде күңел*
*Язмыш җилләрендә сыналып.*
*Яшәп ятыш. Уч төбемдә — өмет.*
*Шөкер итәм мең кат сыналып.*

*Фанилыкның сиратларын кичәм,*
*Ачу томмый кырыс дөньяга.*
*Рәхмәт укып ихлас дога кылам,*
*Йөзем төбәп көн дә кыйблага.*

*Ялган төсләр ялган буяуларда,*
*Заман кулларында пумала.*
*Боек күзләр, җансыз йөзләр аша*
*Дөнья яктылыгы югала.*

*Бәгырьләрне телә нахак сүзләр,*
*Кырау ала җылы хисләрне.*
*Көндез чыра ягып эзләп йөрим*
*Изгелектән калган эзләрне.*

*Каешланган күптән инде күңел,*
*Яшьләр кипкән, ахры, күзләрдә.*
*Явызлыктан түгел, яхшылыктан,*
*Елыйм кайчак җылы сүзләрдән.*

*Бу дөньяда юкка яшәмимдер,*
*Үз бәхетем, сагыш, ярам бар.*
*Калебемне ачып сыенырга,*
*Ышанырга газиз Аллам бар.*

***Ришат хәзрәт Курамшин,***
***Кукмара шәһәре***

### Хушлашу

*Күзләр җитте... Соры яңгыр ява.*
*Күңелемдә җете төсләр уңган.*
*"Соңгы тапкыр дәшим", – дигән кебек,*
*Тәрәзәмә ялгыз яфрак кунган.*

*"Хушлашырга килдем синең белән... –*
*Гүя шулай диде сары яфрак, –*
*Ямьле җәйләр, гүзәл яшел чагым*
*Үтеп китте, ул чор инде ерак...*

*Зәгыйфьләндем һәм өзелеп төштем...*
*Йорт әһеле! Син ваемсыз булма:*
*Гомерең күзе җитеп, минем кебек*
*Мәңгелеккә китәсең онытма..."*



*Безгә язалар*

# Хаҗилар очрашуы

Әгерҗе районыннан быел изге җирләргә 14 кеше хаҗ кылды. Шул җәһәттән Төрдәле һәм Кырынды мәхәлләләре мәчетләрендә хаҗдан кайтучылар белән очрашулар оештырылды. Беренче көндә Төрдәле мәчетенә йөздән артык кеше җыелды, төрле елларда изге гамәлне үтәгән 15 хаҗи да килгән иде. Зөфир хәзрәт хаҗилар белән таныштырды. Район имам-мөхтәсибе хаҗи Габделкәрим хәзрәт быелгы хаҗның үзенчәлекләре турында сөйләде, хаҗның тән һәм мал гыйбадәте икәнен аңлатты. Калган гомеребездә хаҗның савабын югалтмыйча яшәргә кирәклеген искәртте.

Быел район хастаханәсенең элекке баш табибы Рәфыйк Шакировка да хаҗ кылу насыйп булды. Аны Гарәбстанның таба кебек тигез юллары, халкының хаҗиларга хәерһахлы булуы сокландырган; кайбер көннәрдә 14-15 чакрым үтәргә туры килсә дә һич тә арытмавын искә алды.

Элекке "Родина" колхозының алдынгы машина йөртүчесе Рәшит Галләмов 2016 елда Әгерҗенең "Нур" мәдрәсәсен тәмамлады. Тырыш хезмәте өчен ике тапкыр ВДНХның бронза медаленә, "Халыклар дуслыгы ордены"на һәм "Фидакарь хезмәт өчен" медаленә лаек булган Рәшит быел хаҗ кыла алу мөмкинлеген Аллаһтан иң зур бүләк итеп кабул иткән. Кыен чакта Пәйгамбәребезнең (г.с.) хәдисләрен китереп, рухландырып торган юлдашларына — Арча эшмәкәрләренә рәхмәтле ул.

Районыбыз эшмәкәре Илшат Сәхиповка быел икенче тапкыр изге җирдә Аллаһның кунагы булырга язган. Гарәп халкының югары әдәп һәм әхлак иясе булуы, гыйбадәтләренең ихласлыгы, кунакчыл булулары сокландырган аны.

Төрдәле мәхәлләсе имамы хаҗи Зөфир хәзрәт халыкның дингә кайтуын, авылларында корбан чалучыларның ел саен арта баруын куанып сөйләде. Мәчеттә әледән-әле төрле чаралар уздырыла, аларга яшьләр дә тартыла, якташ эшмәкәрләр дә һәрчак ярдәмгә киләләр.

Кырынды мәхәлләсе хәзрәте хаҗи Мөбин Кәримуллин күпләрне борчыган мәсьәләне күтәрде. Җиде яшеннән намазын калдырмаган, туксаннан узган абыстаебыз вафат булгач, мәетне ярдырмас өчен төрле түрәләргә җитүләрен, әмма мәсьәләнең уңай хәл ителмәвен ачынып сөйләде. Ислам дине кануннары буенча яшәгән карчыкның урыс милләтеннән булган ир-ат патологоанатом кулыннан үтүе безнең өчен фаҗигагә тиң, диде ул. Хөкүмәтбез, сәламәтлек саклау министрлыгы мөселман карт-карчыкларны ярмыйча җирләү мәсьәләсен уңай хәл итсен иде дигән теләген җиткерде.

**Рәмзия Шәймөхәммәтова,**
**Әгерҗе шәһәре.**

# Мәдрәсәләр булса иде

Миннән еш кына дингә ничек килүем хакында сорыйлар. Ә бу сорауга җавап бирер өчен сүзне үткәннәрдән башларга кирәктер. Мин Саба районы Тимершык авылында туып үстем. Безнең гаиләдә Аллаһка мәхәббәтне әти тәрбияләде. Әтием — мулла белән абыстай улы, 5 нче бала булып дөньяга килгән. Бабам Миннегали сугыштан исән-имин кайтса да, туган авылында тыныч кына яшәргә язмаган булып чыга. "Муллалыгыңны ташласаң, рәхәтләнеп яшәрсең", - дип шарт куялар аңа. Әлеге шартка күнмәгән өчен бабамны авылдан куалар. 5 баласы белән ялгыз калган әбиемә дә тынгылык булмый: аны өеннән куып чыгаралар. Якты йөз күрсәткән кешеләрнең мунчасында балалары белән яшәргә мәҗбүр була ул. "Без яшәгән 5 мунчаны хәтерлим мин", - дип сөйли иде әтием.

Вакытлар үткәч, бабам авылына кире әйләнеп кайта һәм мулла булып, яңа туган сабыйларга исем кушып, бу дөнья белән хушлашканнарны соңгы юлга озатып, изге эшен дәвам итә. Әнием исә: "Килен булып төшкәндә, мин кайнатам белән кайнанамның исемнәрен белми дә идем. Авылда аларны барысы да "мулла", "абыстай" дип кенә йөртәләр иде",- дип искә ала.

Без гаиләдә 3 кыз үстек. Хәтерлим әле, әтиебез атнаның билгеле бер көнендә безне каршына тезеп бастырыр иде дә сораулар бирер иде. "Син кайсы диннән?", "Пәйгамбәрең кем?" Үзе намаз укымаса да, күңелендә ышану көчле иде аның. Ә менә бертуган абыйсы гарәпчәгә өйрәнеп, 17 яшеннән намазга баскан. Авылыбызда Миннегали бабамның эшен дәвам итте. Мин абый янына йөреп гарәпчәгә өйрәндем. Ә 7нче класста укыган чагымда: "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә укырга кертергә әзерлим сине", - диде. Ләкин шулай килеп чыкты: мин, 9 классны тәмамлап, мәдрәсәдә гел кызлар арасында укып, дин нигезләрен өйрәнәсе кеше, урта мәктәп аттестатын алып, Казан авыл хуҗалыгы институтына агроном белгечлеге буенча укырга кердем. Группада егетләр арасында мин берүзем идем. Группадашым — Актаныш егете Илгиз белән 4 ел дус булып йөрдек тә, диплом алгач, өйләнештек. Яшәргә исә Актаныш ягына, Илгизнең туган авылы Бикчәнтәйгә бабасы янына кайттык. Кайтсак... йортта дини китаплар, намазлык, азан тавышы! Мирзаһит бабай — авылның мулласы икән! Ул миңа элекке теләгемне тормышка ашыруда бик зур этәргеч, таяныч булды. Казан урамнарында йөргәндә матур итеп яулык бәйләгән кызларга кызыгып карый идем. Ә үзем Бикчәнтәйгә килгәч тәвәккәләдем.

Бүгенге көндә апаларым, әнием — барыбыз да намазда. Әтием, кызганычка, арабызда юк. Хәзер инде үзебезнең 3 кызыбыз үсеп килә, алар да дингә тартыла. Минем теләгем: авылларда мәчет каршында мәдрәсәләр эшләсен, Аллаһ кушканны үтәүчеләр күбрәк булсын иде.

**Гөлнара Ганиева,**
**Актаныш районы, Әтәс авылы.**

# “Кабул булган хаҗның бүләге – бары тик җәннәт”



*2018 елда Олы хаҗ һәм Гөмрә (Кече) хаҗ кылырга теләүчеләр иң беренче чиратта нәрсәне белергә тиешләр, әзерлек өчен кайда белем алырга мөмкин – шул хакта Чаллының “Ихлас” мәчете имам-хатыйбы, мөхтәсибәтнең хаҗ мәсьәләләре буенча җаваплы кешесе Илназ хәзрәт Яхин белән сөйләшбез.*

***— Илназ хәзрәт, хаҗ кылырга ниятләгән кеше иң тәүдә нәрсәләрне анык белеп торырга тиеш? Сүзебезне шуннан башлыйк әле.***

— Әгуузу билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, әссаләтү үәссәләәмү галәә расулиһи Мухәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәбиһи әҗмәгыйн. Иң беренче: нәрсә ул хаҗ? Аллаһы Тәгалә безләргә ислам динен җибәрде биш багана, биш баскыч белән: Аллаһтан башка илаһ юк дип шәһадәт китерү, биш вакыт намаз уку, ураза тоту, зәкәт түләү һәм мөмкинчелеге булган кешегә хаҗ кылу. “Мөмкинчелеге булган кешегә” дигән сүз — Аллаһы Тәгаләнең халыкка карата булган бер рәхмәте. Чөнки бөтен кешенең дә малы да юк, сәламәтлеге дә булмаска мөмкин... Ләкин шушы сүзнең асылын аңлап бетермәгән хәлдә, мөселманнарның бу гамәлгә карашы сүлпәнләнә. Асылда ул фарыз. Әйтик, 5 вакыт намаз укыган кеше, бүген намазымны укымыйча торыйм әле, иртәгә укырмын, дип әйтә алмый. Чөнки ул моның гөнаһ икәнен белә. Ә хаҗ турында хаталанып әйтәләр: әйтик, быел бармыйм әле, киләсе елга туганым белән барам, хәләл җефетем белән барам, фәлән кеше бара икән, аның белән барырмын..... Аллаһ каршында үтәргә тиешле фарыз эшен ни беләндер чикләү — хаҗга барырга теләгән кешенең беренче хатасы. Без хаҗга Аллаһ ризалыгы өчен барабыз. Хаҗ ул ике төрле сәфәр: тән сәфәре һәм рухи сәфәр. Тән белән йортыбыздан чыгып китәбез, ят, таныш булмаган урынга җыенабыз. Рухи сәфәр дигәндә, үзебезнең малыбызны, йортыбызны калдырып, Раббыбыз каршысына китүебез күздә тотыла. Ир кеше, өстендәге бер киемен дә калдырмыйча, тәнен ике ак материяга чорнап, Аллаһы Тәгалә каршысына бара. Галимнәр бу ихрам киемен кәфенлек киемен кию белән чагыштыралар: кеше, кәфенлек киеп, бу дөньядан мәңгелеккә китә, ә ихрам киемендә мәңгелеккә китү халәтен кулланып карый. Һәр гамәлнең максаты бар: әйтик, биш вакыт намаз уку — һәрдаим Аллаһны искә төшереп тору, ураза тоту — ач торып,нәфесне тәрбияләү максатында. Хаҗның төп максаты исә — зөһетлек, аскетизм, ягъни дөньядан аерылып тору. Аллаһы Тәгалә бу эш өчен нинди әҗер-савап бирә соң?

— Хаҗиларның икенче хатасы — шушы әҗер-савапларны белеп бетермәү һәм аңа бик сүлпән карау. Аллаһ нәрсә вәгъдә итә? Пәйгамбәребез (г.с.) әйтә: “Бөтен хаклары, бөтен шартлары үтәлгән хаҗның әҗере юк — җәннәттән кала”. Мөселман кешесенең туганнан алып үлгәнчегә кадәр максаты шул да инде, ягъни бу дөньяда нәрсә өчен яши? — Аллаһ ризалыгы өчен, Аллаһ ризалыгына ирешеп, җәннәткә керү өчен. Ә монда Аллаһ безгә шундый мөмкинчелек биреп тора: хаҗ кылып, тиешенчә хакларын үтәп кайтсаң — үзеңә җәннәт алып кайтасың. Пәйгамбәребез (г.с.) әйтә: “Гөнаһлы гамәлләр кылмыйча һәм бозык сүзләр сөйләшмичә хаҗ кылучы кеше анадан туган бала кебек пакьләнеп, гөнаһларыннан чистарынып кайтыр”, ди.



***— Хаҗилар арасында иң еш күзгә ташланган хаталанулар нәрсәдән гыйбарәт?***

— Иң гадиләрен әйтсәм... Мәсәлән, ихрам хәлендә тыелган эшләр бар: хуш исле әйберләр сөртү, төкләрне йолку, тырнакларны кисү, бәхәсләшү, бозык сүзләр сөйләү, гөнаһлы эшләр эшләү. Ирләргә тегелгән кием кию, башны каплау тыела. Ихрам хәлендә (ул 2-3 көн була) кулын тулысынча хуш исле сабын белән юа икән, әлеге гамәле өчен соңыннан бер сарык корбан чалырга тиеш була. Кеше гыйлемсез хәлдә килсә, мин нишләргә тиеш дип, еш кына югалып кала. “Ярар, анда җитәкче була, аның белән йөрермен әле”. — дип җиңел генә уйлап килүчеләр була. Ә бит төрле чак була: җитәкче авырып китә, яки үзенең гыйлеме җитми, яки хаҗины бу җитәкчедән аералар... Адашып киткән хаҗи да, гыйлеме булмаса, хата өстенә хата эшләргә мөмкин. Шуңа күрә хаҗга әзерлек курсларына йөреп гыйлем алу бик мөһим.

***— Укучылар өчен әлеге курсларның кайда һәм кайчан булачагын, хаҗ бәяләрен дә әйтеп китсәк...***

— Укулар ноябрь аеннан, Сидоровка бистәсендәге “Ихлас” мәчетендә үткәрелә, һәр якшәмбе сәгать сигездә башлана. Бәяләргә килгәндә, эконом-тур 125 меңнән башлана. Өстәмә мәгълүматны Чаллы мөхтәсибәтеннән, 48/09 адресы буенча урнашкан “Нур-Ихлас” мәчетеннән дә (телефоны 56-65-99) алырга мөмкин.

# Бәхетле булыйм дисәң…

“Хәзинә” мөселман балалар клубы — бүгенге катлаулы заманда сабыйларны, гомумән, киләчәк буынны тәрбияләүдә искиткеч җаваплы һәм саваплы эш алып бара. Ислам дине, шәригать кануннары белән кечкенәдән танышып үскән бала күңелендә мәрхәмәтсезлеккә урын юк. Чөнки клубның бар эшчәнлеге, анда узган чаралар да бары тик шәфкатьлелек белән сугарылган.

13 октябрьдә, Өлкәннәр ункөнлеге уңаеннан, “Әбием-әбекәем” дип исемләнгән кичә уздырылды. Биредәге кызлар төркеменең әбиләре, дәү әниләре кунакка чакырылып, онытлары аларга матур итеп сүрәләр укыдылар; мәгънәле җырлар да җырланды, хикмәтле гыйбарәләр, хәдисләр дә телгә алынды. Кунак ашы — кара-каршы дигәндәй, үз чиратында әбиләр дә җавапсыз калмадылар: истәлекләр белән уртаклаштылар; сөенечле күз яшьләрен тыя алмыйча, мөгаллимәләргә эчкерсез рәхмәтләрен белдерделәр. “Без ислам диненә соңлап, картайган көннәрдә генә килдек. Яшьлегебездә андый мөмкинлек булмады, заманасы шундый иде. Аллага шөкер, оныкларыбызга кечкенәдән үк шәригать кануннары белән танышырга бөтен җай да бар, мондый клубның булуы үзе үк хәзинә бит”, - диеште алар беравыздан.



“Кемнең бәхетле буласы килә?”

Дәү әниләрнең авызыннан яңгыраган бу сорауга ак яулыклы кызлар барысы бер булып кул күтәргән иде.

“Бәхетле буласыгыз килсә, шушы юлдан — ислам юлыннан беркайчан да тайпылмагыз, балалар”, - дип, бәхетле булуның серен дә ачты дәү әниләр.

“Хәзинә” клубы ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Чаллы мөхтәсибәте каршында 2012 елдан бирле эшләп килә. Аның алыштыргысыз җитәкчесе Ләйсән Әхмәтшина да, кичәне алып барган мөгаллимә Гөлшат Мөсифуллина да, килгән кунаклар да ата-анага, өлкәннәргә кадер-хөрмәт турында сүз алып, балалар күңеленә янә бер тәрбияви орлык салдылар. Кызлар исә дәү әниләренә бүләкләр тапшырдылар. Клубта кече тәрбияче булып эшләүче Кәлимуллина Әнисә апаларына, олы йөрәкле булганы өчен, аерым бүләк әзерләгәннәр иде!

Чәй өстәле артында дәвам иткән матур кичәне башка уку йортларына, бик күп гаиләләргә үрнәк итеп күрсәтерлек шәфкатьлелек чарасы дип тә исемләргә мөмкин.

**Айгөл Әхмәтгалиева.**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**27 октябрь 16 сәг.**
**фактта 27 октябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**